**СОВЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2021 елның 31 нче мае                                                    № 13-36

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 нче февралендә кабул ителгән 7-21 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә" гә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2021 елның 5 нче февралендә кабул ителгән 7-21 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә" гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

1 өлешнең 9 пунктында «җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак, аның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату йә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 өлешнең 12 пунктын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса " сүзләрен өстәргә»;

5 өлештә "йә авыл җирлеге депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 16 статьяда:

1 өлешнең беренче абзацында "этика" сүзләреннән соң сүзләр өстәргә
җирлек Советы тарафыннан раслана торган документлар,»;

2 өлештә «тиешле комиссия» сүзләрен» җирлек Советы карары белән төзелә торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча комиссия «сүзләренә алмаштырырга»;

3) 17 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында "җирлек" сүзләреннән соң түбәндәге сүзләр өстәргә:
үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы комитет,»;

4) 19 статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә «органнар» сүзләрен «комиссияләр " сүзләренә алмаштырырга»;

5) 21 статьяда «кабул итәргәхокуклы» сүзләрен «кабул итә»сүзләренә алмаштырырга .

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы

Д.С.Гайнуллин